*Кушымта 1*

**Республикакүләм «Мин татарча сөйләшәм!»**
**акциясенең Мәктәпләр бәйгесенең Нигезләмәсе**

26 апрельдә, бөек татар шагыйре Габдулла Тукайны искә алу көнендә, Бөтендөнья татар яшьләре форумы Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы Казан шәһәре Башкарма комитеты белән берлектә «Мин татарча сөйләшәм!» республикакүләм акциясен үткәрә. Әлеге акция кысаларында Татарстан Республикасы мәктәпләре арасында татар телен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә юнәлтелгән бәйге үткәрелә. Бәйгедә җиңгән 20 такым алга таба «Казан Квест» уенына чакырыла.

«Казан Квест» - 2025 елның 14 апрелендә Бөтендөнья татар яшьләре форумы, Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ярдәмендә үткәрелә торган татар телендә квест-уен.

**Катнашучылар**

Бәйгедә гомуми белем бирү оешмаларының **7-11 сыйныф** укучылары катнаша ала. Мәктәптән бер команда чакырыла: 7 укучы һәм 1 куратор. Татар телендә камил сөйләшкән укучыларга биремнәрне башкару җиңелрәк булачак. Кураторның бурычлары: такымның эшен күзәтеп тору, координацияләү, аларны хәбәрләп тору, **әмма** уенга катышмау, ягъни эшләрнең, җавапларның нәтиҗәләренә йогынты ясамау сорала.

**Биремнәр**

Бәйгедә катнашу өчен https://forms.yandex.ru/u/67c6a5ea4936398abb4db95d/ сылтамасы аша кереп, **31 нче мартка** кадәр гаризаны тутырырга һәм эшләнгән биремнәрен беркетеп җибәрергә кирәк.

**1 нче бирем**. *Такым (команда) белән вертикаль клип төшерү*. Татар дөньясының идеаль киләчәген сез ничек күз алдыгызга китерәсез? Ул нинди булыр? Шуның турында кыска вертикаль видео төшерегез (дәвамлылыгы - 1 минутка кадәр). Әлеге видеоклипны ВК сәхифәсенә урнаштырып, безгә сылтаманы җибәрегез. Сылтама гариза тутырганда беркетелә.

***Критерийлар:***

Барлык такымның катнашуы *(5 балл)*
Татар телендә камил сөйләшү *(10 балл)*
Видеоязманың кызыклы, хәтта көлкеле, креатив, иҗади булуы *(10 балл)*

Видеоязманың информатив, продуктив һәм аңлаешлы булуы, оригиналь һәм киң фикер йөртә белү *(15 балл)*

Видеоязманың яхшы сыйфатта булуы (съемка, тавыш) *(10 балл)*

**2 нче бирем.** *Такым (команда) белән проект әзерләү.* Хәзерге көндә татар мәдәниятен саклауга, үстерүгә һәм популярлаштыруга ярдәм итә алган проект язарга һәм презентациягә тупларга. Презентация гариза тутырганда беркетелә.

***I. Проектны язу шартлары.***

Проектның темасы татар мәдәнияте (тел, тарих, сәнгать, әдәбият, музыка, театр, it технологияләр, медиа һ.б.) белән бәйле булырга тиеш.

Проект актуаль проблеманы хәл итәргә һәм җәмгыятькә файда китерергә тиеш.

***II. Проектны язганда җавап бирергә кирәк булган сораулар.***

Сезнең проект ничек атала?

Ни өчен бу теманы сайладыгыз?

Проект кайсы проблеманы хәл итә?

Ул кем өчен файдалы булачак?

Нинди охшаш проектлар бар? Сезнеке нәрсә белән аерыла?

Проект нинди этаплардан тора?

Проектка аудиторияне ничек җәлеп итеп була?

Проектның ахыргы нәтиҗәсе нинди булырга тиеш?

***Критерийлар:***

Актуальлек һәм әһәмиятлелек *(15 балл)*

Практик файда – Проектны тормышта кулланып буламы? Ул җәмгыять өчен файдалы була аламы? *(15 балл)*

Креативлык һәм үзенчәлеклелек *(15 балл)*

Презентациянең сыйфатлы һәм аңлаешлы булуы *(5 балл)*

**3 нче бирем.** *Дәүләт оешмаларын һәм хосусый оешмаларны икетеллелеккә тикшерү*. Оешмалар элмә такталарын кайвакыт хаталы рәвештә тәрҗемә итәләр, яки, гомумән, татар телендә мәгълүматны язып чыгармыйлар. Сезнең максат - шундый элмә такталарны (оешманың исеме, эш графигы, төрле кагыйдәләр һәм элмә такталар) табарга һәм тикшерергә.

Җавапны презентация форматында эшләгез: һәр слайдта хаталы элмә такта белән фото + оешманың исеме һәм адресы булырга тиеш. Фото янында хатаны дөресләп җибәрегез. Татарча вариант булмаса, төзәтү кирәк түгел. Презентацияне шулай ук гариза тутырганда махсус урынга беркетегез.

Критерийлар: аңлаешлы булу, барлык такымның катнашуы, актив булу, хаталарны дөрес төзәтү, татар телендә язылмаган элмә такталарны табу. (1 элмә такта – макс. 5 балл)

Җавапларның килеп житүенә шик туса, электрон почтага язып җибәрә аласыз: tatdozor@gmail.com. Тема – «Казан Квест». Мәктәп исемен язып җибәрү мәҗбүри.

## «Казан Квест»

Мәктәпләр бәйгесендә җиңгән 20 такым алга таба «Казан Квест» уенына чакырыла. «Казан Квест» уены **14 апрель** көнне Казан урамнарында узачак. Очрашу урыны - Бауман сәгате.

Уен квест форматында эшләнгән: такымнар биремнәрне үтәп нокталар буенча йөриячәк. Нокталар саны такымнар санына туры киләчәк. Уен барышында такымнар оешмаларны икетеллеккә дә тикшерәчәк.

Уенның тәртибе, концепциясе һәм темасы бәйгене узган такымнарга җиткереләчәк. Кураторлар белән чат төзелә һәм барлык мәгълүмат шунда урнаштырыла.

## Нәтиҗә чыгару

**Гариза** һәм **җаваплары 31 нче мартка** кадәр кабул ителә. Гариза тутыру мәҗбүри.

Мәктәпләр бәйгесендә җиңгән 20 такым алга таба «Казан Квест» уенына чакырыла. Оештыручылар җавапларны тикшергәннән соң, «Казан Квест» уенына узган такым кураторлары белән чат төзиләр. 3 апрельгә кадәр кураторларга хәбәр биреләчәк.

**Мәктәпләр бәйгесендә катнашкан һәр мәктәпкә катнашучы дипломы бирелә.**

Оештыручылар: Бөтендөнья татар яшьләре форумы, Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Казан шәһәренең Башкарма комитеты.

Барлык сораулар буенча: **tatdozor@gmail.com,** +79872078165 (Эльмира)

Без Вконтакте челтәрендә: **https://vk.com/qazanquest**

Безнең Telegram-канал: **https://t.me/qazanquiz**